# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**27 ноябрь 2020 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставы нигезендә 2020 елның 27 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2021 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);
- Авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Беренче Май бистәсендә ике телдә язылган урам исемнәре һәм йортлар күрсәткечләрен сатып алу (әзерләү);
- Беренче Май поселогында юлларны кардан чистарту;
- Беренче Май т. п. мөселман һәм православие зиратларында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу, киртәләр ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, киртәләр кую).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 154 граждан җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 87.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 87, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa:

«Сез, 2021 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол

хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);

- Авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Беренче Май бистәсендә ике телдә язылган урам исемнәре һәм йортлар күрсәткечләрен сатып алу (әзерләү);

- Беренче Май поселогында юлларны кардан чистарту;

- Беренче Май т. п. мөселман һәм православие зиратларында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу, киртәләр ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, киртәләр кую).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге башлыгы А.И.Закиров